КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

14.10.2024 №204-п

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» XI гомумроссия конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 13 маендагы 56-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» XI гомумроссия конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 13 маендагы 56-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә «XI» цифрын төшереп калдырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:»;

1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктта «XI» цифрын төшереп калдырырга;

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» XI гомумроссия конкурсын үткәрү турында» күрсәтелгән боерык белән расланган Нигезләмәдә:

исемдә «XI» цифрын төшереп калдырырга;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен, оештыру һәм үткәрү шартларын билгели.»;

1.3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Конкурс 30 декабрьгә кадәр үткәрелә.»;

икенче абзацта «шул исәптән, махсус,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.1 пунктның икенче абзацында «(алга таба – ММЧ)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Конкурста аерым журналистлар, законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Россия Федерациясе массакүләм мәгълүмат чаралары (алга таба – ММЧ) катнаша.»;

3.2 пунктта:

«аерым авторлар, иҗат коллективлары һәм төркемнәре» сүзләрен «аерым журналистлар» сүзләренә алмаштырырга;

«(законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Конкурска гариза бирүче бер номинациягә бер генә документ тапшыра ала.»;

4.1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Конкурста катнашу өчен алдагы конкурска йомгак ясалган датадан алып чираттагы конкурска гаризалар кабул итү тәмамлану датасына кадәр булган чорда дөнья күргән эшләр кабул ителә.»;

4.3 пунктта:

«а» пунктчасының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы мәкаләләр (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар), төп нөсхә яки күчермә нөсхә рәвешендә (сканер аша чыгарылган вариантта) тапшырыла. Язмалар редакция мөһере (булган очракта) һәм җитәкче имзасы таныкланган булырга тиеш;»;

«д» пунктчасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) аерым журналистлар өчен:»;

икенче абзацка «һәм шәхесне һәм журналистның вәкаләтләрен раслый торган редакция таныклыгы йә башка документ (копия);» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «авторлар коллективлары» сүзләрен «аерым журналистлар» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «б» – «е» пунктчаларында» сүзләрен «б» – «д» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, 6 кат, 608 нче кабинет, ММЧ бүлеге, «Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсына» дигән тамга белән. Телефон: 8 (843) 570-31-12.»;

4.6 пунктта татарча текст үзгәрешсез кала;

4.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирүченең «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия булуы;

Гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.»;

4.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурста катнашуга рөхсәт бирелмәгән очракта, Гариза бирүче Конкурста катнашу өчен гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганчы әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килә торган яңа гариза бирергә хокуклы.»;

4.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Конкурс йомгаклары конкурс комиссиясе тарафыннан ясала һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Татар халкының тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган иң яхшы эшләр циклы»;

«Социаль челтәрләрдә татар телен һәм мәдәниятен популярлаштыру буенча иң яхшы видеопроект».»

7.8 пунктта «авторныкы, иҗат коллективыныкы» сүзләрен «журналистныкы» сүзләренә алмаштырырга;

8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан

Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында агымдагы финанс елына Конкурс үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән финанслана.»;

8.2 пунктта «162,0 мең сум» сүзләрен «314 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

8.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.3. Конкурста җиңүчеләр чәчәкләр, дипломнар һәм акчалата премияләр белән түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинацияләр | Премияләр саны | Урын | Гомуми сумма (мең сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | «Татар халкының тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган иң яхшы эшләр циклы» | 3 | 1 место | 64 000 |
| | | | 2 место | 53 000 |
| | | | 3 место | 40 000 |
| 2. | «Социаль челтәрләрдә татар телен һәм мәдәниятен популярларлаштыру буенча иң яхшы видеопроект» | 3 | 1 место | 64 000 |
| | | | 2 место | 53 000 |
| | | | 3 место | 40 000 |
| Барлыгы | | | | 314 000»; |

8.4 пунктта «Агентлык җитәкчелегенә язылган рәсми хатта» сүзләрен «анкетада» сүзенә алмаштырырга;

8.5 пунктта «Агентлык җитәкчелегенә язылган рәсми хатта» сүзләрен «анкетада» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 9.3 пункт өстәргә:

«9.3. Конкурста катнашу рөхсәт ителгәннән соң «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып танылган катнашучы Конкурс нәтиҗәләре буенча диплом белән бүләкләнми һәм аңа премия бирелми.

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

| Конкурста катнашу өчен анкета-гариза | |
|---|---|
| Гариза бирүче (массакүләм мәгълүмат чаралары исеме; автор*, авторлар коллективы) | Гариза бирүче (массакүләм мәгълүмат чаралары исеме; автор*, авторлар коллективы) |

| | |
|---|---|
| Номинация | Номинация |
| Конкурс эше | Конкурс эше |
| Эчтәлеге | Эчтәлеге |
| Адрес | Адрес |
| Телефон | Телефон |
| Электрон почта | Электрон почта |
| Гариза бирүченең банк реквизитлары (банка исеме, ИНН и КПП, БИК банка, исәп-хисап счеты счета | Гариза бирүченең банк реквизитлары (банка исеме, ИНН и КПП, БИК банка, исәп-хисап счеты счета |
| ИНН (физик затлар өчен) | ИНН (физик затлар өчен) |
| СНИЛС (физик затлар өчен) | СНИЛС (физик затлар өчен) |

Түбәндәгеләрне раслыйм:

журналистларның «Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсына җибәрелгән конкурс эшләре өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын бозмый.

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормыйм.

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

** Гариза бирүче авторлар коллективы булган очракта күрсәтелә

Дата ___________________

Имза ________________________ ________________________________

(фамилия һәм вазыйфа тулысынча (булган очракта)»

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________________,
яшәү адресым_______________________________________________
_______________________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________
_______________________________________________________________________________
_________________________________, «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) «Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

Дата _________________

______________________________________________/___________
(Ф.И.Ат.ис.* һәм персональ белешмәләр субъекты имзасы)

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә»;

3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсы турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ___________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)
___________________________________________________________________________,
(почта адресы)
___________________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)
___________________________________________________________________________,
(телефон номеры)
«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) «Татар дөньясын иң яхшы яктыртуга журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Татар рухы һәм каләм» – «Татарский дух и перо» гомумроссия конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Җенес | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Гражданлык | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (төре, сериясе, датасы, кем тарафыннан бирелүе) | | |
| | Яшәү урыны, теркәлү урыны | | |
| | Телефон | | |
| | Электрон почта адресы | | |
| | Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет турында белешмәләр | | |
| | ИНН | | |
| | СНИЛС | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Персональ белешмәләрнең категориясе] | | |
| | [Персональ белешмәләрнең исемлеге] | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ____________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.
Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.
Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат

тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

______________(персональ белешмәләр субъекты имзасы)
______________ (число, ай, ел)».

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев